| | | |
|---|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

17.08.2022 г.Казань № 786

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 21 июлендәге 488 номерлы боерыгы белән расланган Билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга һәм һөнәри белем бирүне үткән яисә мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча өстәмә һөнәри белем алган гражданнарга шәхси эшкуар сыйфатында дәүләт теркәвенә алынганда, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куйганда бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтүне дә кертеп, эшсез гражданнар тарафыннан эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлауга булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентының аерым категория гражданнары өчен гамәлгә кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 елда халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүне оештыру үзенчәлекләре турында» 2022 елның 16 мартындагы 376 номерлы карары нигезендә боерык бирәм:

Билгеләргә:

1) Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган

гражданнарга һәм һөнәри белем бирүне үткән яисә мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча өстәмә һөнәри белем алган гражданнарга шәхси эшкуар сыйфатында дәүләт теркәвенә алынганда, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куйганда бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтүне дә кертеп, эшсез гражданнар тарафыннан эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлауга булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 21 июлендәге 488 номерлы боерыгы белән расланган Билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга һәм һөнәри белем бирүне үткән яисә мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча өстәмә һөнәри белем алган гражданнарга шәхси эшкуар сыйфатында дәүләт теркәвенә алынганда, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куйганда бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтүне дә кертеп, эшсез гражданнар тарафыннан эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлауга булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентының түбәндәге категорияләрнең берәрсенә карый торган, туры килә торган эш эзләү максатларында теркәлгән гражданнар өчен дә 2022 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә булуын:

эштән азат ителү куркынычы янаган гражданнар (оешма бетерелүгә яки шәхси эшкуарның эшчәнлеге туктатылуга, оешмада, шәхси эшкуарда хезмәткәрләрнең саны яки штаты кыскартылуга һәм алар белән хезмәт шартнамәләрен өзү ихтималлыгына бәйле рәвештә эштән китәргә җыенучы гражданнар);

эш бирүче зат инициативасы буенча тулы булмаган эш көне (смена) һәм (яки) тулы булмаган эш атнасы режимына күчерелгән гражданнар;

эшне вакытлыча туктатып тору турында карар кабул иткән эш бирүчеләр белән хезмәт мөнәсәбәтләрендә торучы гражданнар;

үзләренә карата бөлгенлек (банкротлык) турында процедуралар кулланылган эш бирүчеләр белән хезмәт мөнәсәбәтләрендә торучы гражданнар;

эш хакын сакламыйча отпуск ялларында булган гражданнар;

эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче гражданнар;

2) әлеге боерыкның 1 пунктындагы өченче-җиденче абзацларында күрсәтелгән гражданнар, билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга һәм һөнәри белем бирүне үткән яисә мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча өстәмә һөнәри белем алган гражданнарга шәхси эшкуар сыйфатында дәүләт теркәвенә алынганда, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куйганда бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтүне дә кертеп, эшсез гражданнар тарафыннан эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлауга булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен тапшырылуы мәҗбүри булып торган документларга өстәмә рәвештә, категорияләренә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасының халыкны эш

белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләренә түбәндәге турында карар кабул ителүен раслый торган, эш бирүче тарафыннан бирелгән түбәндәге документларның берсен тапшыралар:

оешманы бетерү яки шәхси эшкуар тарафыннан эшчәнлекне туктату турында;

оешмада, шәхси эшкуарда хезмәткәрләр санын яки штатын кыскарту һәм хезмәт шартнамәләрен өзү ихтималлыгы турында;

эш бирүче тарафыннан тулы булмаган эш вакытын билгеләү турында;

эшләрне туктату яки вакытлыча туктатып тору турында;

хезмәт хакын сакламыйча гына отпусклар бирү турында;

хезмәткәрләрне азат итү буенча чаралар үткәрү турында.

Министр Э.Ә.Зарипова